**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА ЯКУШКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**НУРЛАТСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯКУШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

Якушкино
авылы

**30 октября 2019 г.** **№ 3**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районының "Якушкино авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 13 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Салдакай авылы, Үзәк урамы, 18 нче йорт адресы буенча урнашкан, авыл мәдәният йорты бинасында, Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2019 елның 16 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Салдакай авылы, Үзәк урамы, 18 нче йорт адресы буенча урнашкан, авыл мәдәният йорты бинасында, Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Территориаль билге буенча гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне сайлау тәртибе.

4. Гражданнар Җыенының этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлегенең Салдакай авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы

студентлардан кала, 2020 елда һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:
торак пункт чикләрендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

- су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару;
- зиратларны карап тоту;
- урам утларын ремонтлау һәм карап тоту

«ӘЙЕ» «ЮК».

6. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында һәм Салдакай авылы, Үзәк урам, 12А йорты адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырырга (игълан итәргә).

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Якушкино авыл җирлеге башлыгы Хәмидуллин Х.Х.